МИЛЛИ РУХ

# ЯКТЫ РУХЫ БЕЛӘН БӘХЕТЛЕ



*Бәхетлеме син? —*
*дип сорыйсыз сез,*
*Ничек аңлыйсың бит бәхетне,*
*Мин бәхетле, халкым якын иткән*
*Җыр- моңнарым белән бәхетле.*

*Мин бәхетле, чөнки бу дөньяда*
*Алтын-көмеш коймый бәхетне,*
*Мин бу җирдә*
*саф хисләрем белән,*
*Якты рухым белән бәхетле.*

Бәхетне менә шулай аңлый гомере буе шушы кыйблага карап яшәгән халкыбызның ак йөзе Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе шагыйрә Резеда Вәлиева.

Ә безгә Оренбург өлкәсе Әсәкәй районы, Самара өлкәсе Гали авылы кешеләренә аның белән очрашу бәхете апрель аенда бөек Тукаебыз иҗатына багышланган чараларда насыйп булды.

20 апрельда Яңа Солтангол мәктәбе укытучылары һәм укучылары Резеда ханымны зур ихтирам белән аның иҗатына багышланган композиция әзерләп каршыладылар. Соңыннан аның чыгышын йотлыгып тыңладылар.

Халкыбызның мәртәбәле шәхесенең тормыш юлы иҗаты киләчәк буынга зур үрнәк булып тыңлаучылар күңелендә уелып калды.

Мәктәп укытучылары рәхмәтләрен әйтеп тагын да шундый мәртәбәле татар шәхесләре белән очрашуны оештырырга сорап калдылар.

Без рәсәй татарлары мондый чараларга бик мохтаҗ булып яшибез.Яшьләребез, балаларыбыз алдында Резеда апа кебек шәхесләр белән очрашу бәяләп бетергесез рухи үрнәк.

Үзегез уйлап карагыз: 79 яшендә Әсәкәй район мәдәнияте хезмәткәрләре чакыруы буенча Казаннан рейслы автобуска утырып кем килер иде? Ә ул килде. Чөнки аның тынгысыз йөрәге татар рухын үзе исән чагында читтәге милләттәшләренә дә һәм аларның балаларына да җиткерәсе килә. Өч көн рәттән очрашулар үткәрелде аның катнашында.

21 апрель көнне Самара өлкәсе Гали авылында "Бердәмлек" ассоциасенең беренче карлыгачы булып Габдулла Тукай иҗатына багышланган конкурс үтте. Анда Резеда апа жюри рәисе вазифасын үтәде. Бу конкурста төрле номинацияларда беренче сыйныфтан алып унберенче сыйныф балалары Оренбург өлкәсе Әсәкәй, Самара өлкәсе Похвистнево районнарыннан катнаштылар. Балалар бик тырышып бөек шагыйребез иҗаты буенча иншалар (сочинение) язып, рәсемнәр ясап күргәзмә оештырганнар иде. Ә сәхнәдән бөек шагыйребезнең шигырьләре, җырлары, әкиятләре яңгырады.

Резеда апа конкурсны ачып җибәргәндә һәм йомгаклаганда да Тукаебызга багышлап язган шигырьләрен шундый сәнгати осталык белән башкарды, залда озак алкышлар тынмый торды. Чакырылган кунагыбызны читтә яшәгән татарларда туган телебезгә һәм татар әдәбиятына карата булган ихтыяҗ шатландырды. Ул конкурста җиңүчеләргә бик куанып үзенең автографлы китапларын бүләк итте. Ә татар җәмгыяте рәисләре аның китапларын сатып алып китапханәләргә бүләк иттеләр. Менә шундый изге игелекле эшләр башкарды безнең хөрмәтле кунагыбыз.

22 апрельда Әсәкәй район милли-мәдәни мөхтәрияте татар теле һәм мәдәнияте проблемаларына багышланган киң җәмәгатьчелек каршында киңәшмә уздырды. Бу киңәшмәгә җирле хакимият башлыклары, укытучылар, мәдәният хезмәткәрләре, мәктәп укучылары, хезмәт ветераннары чакырылган иде. Резеда апаның урыны бу киңәшмәдә президиум өстәле артында булды. Киңәшмәдә Әсәкәй район башлыгы Николай Макаров та катнашты. Район милли-мәдәни мөхтәрияте башлыгы Илдус Давлятов чыгышыннан соң укытучылар, мәдәният хезмәткәрләре туган телне һәм татар мәдәниятен үстерүдә алда торган проблемаларны төрле яклап сүрәтләделәр.Соңыннан район башлыгы чыгыш ясады. Ә Резеда апаның туган телебезгә татар мәдәниятенә карата булган мәгънәле чыгышы һәм аның ахырын шигырь юллары белән тәмамлауы залда утыручыларны сокландырды да уйландырды.

Туган телгә карата гаиләдә хөрмәт тәрбияләргә кирәк, гореф-гадәтләребезне онытмаска, татар мәдәниятен алга таба үстерергә кирәк дигән сүзләр тыңлаучыларның хисләрен уятып тирән уйларга чумдырды.

Киңәшмәдән соң район үзәшчән артистлары концерты булды. Район мәдәният йорты каршында эшләп килгән "Туган тел" рәисе Сания Гадельшина Резеда Вәлиеваның берничә шигырен сәхнәдән сөйләде. Халык бик җылы кабул итте аның чыгышын.

Татарстан кунагы концертта Тукайга багышланган шигырьләрен һәм татар тормышының төрле чорларын, тасвирлаган әсәрләрен сәхнәдән сөйләп тамашачыларның дәррәү алкышларын һәм чәчәкләрен кабул итте.

Концерттан соң тамашачылар Резеда апа янына килеп аңа исәнлек һәм чиксез рәхмәтләр әйтеп автографлар алдылар. Һәм ул чиксез рәхмәткә лаек та. Моңа дәлил аның шигырь юллары:

*Бәхетлемен "Рәхмәт" сүзе алсам,*
*Күңелләргә шәфкать*
*нуры салсам,*
*Нәни генә бер игелек кылсам,*
*Ваклыклардан өстен кала алсам.*

**Мондый очрашулар кабатланып торсын иде дигән теләк белән**
**Әсәкәй район мәдәният йорты директоры,**
**РФ атказанган мәдәният хезмәткәре**
**Зәйтүнә ВАЛИШИНА.**

**Фотода:** Резеда Вәлиева.

ТОЛЕРАНТНОСТЬ

# Встреча этнокультур города Бугуруслан

Радушно распахнул свои двери центр немецкой культуры «Возрождение» в весенний субботний полдень, и здание наполнилось детскими и взрослыми голосами. Словно добрые соседи, встретившиеся после долгой разлуки, хозяева и гости приветствовали друг друга, предвкушая радость понимания и познания творческих возможностей человека, влюбленного в свой родной язык, культуру.

Состоялась необычная встреча, встреча этнокультур города. В зрительном зале удобно устроились представители разных национальностей: немецкой, русской, татарской.

На импровизированной сцене учащиеся гимназии и студенты педагогического колледжа разыграли инсценировку по сказкам братьев Грим «Белоснежка» на немецком языке, представители татарского центра «Туган тел» порадовали зрителей песнями, сценками, рассказами на татарском языке. Восторженно была встречена завоевавшая популярность студенческая вокальная группа «Юни вельт», в исполнении которой звучали русские и немецкие песни.

Разные языки и наречия не разделяли, а объединяли людей. Казалось, что каждый из присутствующих знал и помнил все языки, и не было необходимости перевода объяснения.

Это встреча стала итогом большой творческой работы членов студенческого клуба «Диалог культур» (ГОУ СПО «ПБК» г. Бугуруслан) и его активистов — Овсянниковой Ирины, Искандаровой Регины и Овчинниковой Марины

Зрителям был представлен Проект «От познания этнокультур к взаимодействию, единению и дружбе». Активисты клуба исполняют песни, как на языках национальных народов России, так и на иностранных, пишут исследовательские работы, организуют различные мероприятия.

Проект, написанный творческой группой, который озвучила Овсянникова Ирина, прозвучал словно призыв не только к продолжению творческого единения, но и к взаимодействию этнокультур и созданию единого координационного центра для более плодотворной работы во благо подрастающего поколения!

**Нурия ТУРСУНБАЕВА,**
**преподаватель Бугурусланского педагогического колледжа.**

КНИЖНЫЕ НОВИНКИ

# О Бугуруслане на татарском языке

**В очередных номерах нашей газеты, мы уже рассказывали об этой книге. Сегодня, по просьбе читателей и с согласия автора М.Г.Закирова, публикуем окончание из книги о Бугуруслане.**

Тимер юлы үткәннән соң шәһәрдә һәм уездда предприятиеләр барлыкка килә. Богырыслан станциясендә пар белән эшләнә торган тегермән, элеватор корыла, банк ачыла, эшчеләр саны арта.

Шәһәр тормышында күренекле вакыйга булып, 1889 елны земство идарәсе барлыкка килә. Ул идарә мәгариф, мәдәният үстерү, шәһәрне төзекләндерү эшләрен алып бара. Бу эшкә идарәнең җитәкчесе Николай Николаевич Рычков күп көчен куя.

1824елда шәһәрдә бер генә башлангыч мәктәп булса, гасырның азагында хатын — кызлар гимназиясе эшли, уезд училищесында малайлар да белем ала башлыйлар. Шәһәрдә китапханә дә эшли. Шәһәрнең культурасын күтәртү исәбен уйлап, 1900 елда Н.Н. Рычков гаризасы буенча Гоголь исемендәге театр ачыла. Рычков үзе аның мөдире дә, режиссеры да, артисты да була, үз акчасына декорацияләр, костюмнар сатып ала. Театрда Гоголь, Островский язган пьесалар куела.

Дин ягын ачыкласак, шәһәрдә һәм уездда төрле милләттәге халык яшәгәч, алар арасында христианнар (православныйлар, католиклар, староверлар), мөселманнар — һәрберсе үзләренең диннәренә табынганнар, һәрбер диннең йолалар кылу, уку йортлары да булган. Шәһәр уртасында зур бер майданда Спасо — Вознесенский соборы корылган, шуңа күрә янәшәдәге урам да Соборный дип аталган. Кинәле елгасына таба хатын — кызлар монастыре бер кварталга сузылган. Биек кирпич стена эчендә Покров исемен йөрткән собор һәм берничә часовнялар да булган. Монашкалар бишәр — алтышар ике этажлы таш биналарда яшәгәннәр, үзләренең җирләрендә иген, бәрәңге һәм яшелчәләр үстереп тукланганнар. Шул тирәдәге урам да Монастырский дип аталган.

Русларның иске мазарында әле дә Успенский чиркәүе эшли. Христиан халкы үзләренең бәйрәмнәрен билгеләп үтәләр, йолаларын уздыралар.

Шәһәрдә христианнарның дини — рухани училищесы, семинариясе булган, анда дин әһелләре, дини мәктәпләргә укытучылар әзерләгәннәр.

Староверларның Проломный урамында кирпичтән төзелгән чиркәүләре булган, аны сәүдәгәр Печерский, староверлардан акча җыеп төзегән. Шәһәр тирәсендәге Елатомка, Староверовка һәм башка авылларда староверлар да әзәрлекләүдән качып яшәгәннәр.

Богырыслан тимер юлы станциясе артында Александровка поселкасында Екатерина — патша вакытында Русияга киләп немец халкы күчеп килеп, урнашканнар. Католикларның үзләренең дини йортлары булган.

Мөселман халкы үзләренең динен, нинди генә кысулар булса да, бер дә югалтмаганнар. Хәзергә Тукай исеме йөрткән урамда кечкенә булса да мәйдан булган. Шунда агачтан бик матур манаралы мәчет салынган, янында мәдрәсә бинасы да барлыкка килгән. Ул бинаs советлар чорында татар мәктәбенә бирелгәннәр. Хәзергә Тукай исемендәге татар мәдәнияте йортында да мәчет һәм мәдрәсә булган. Шәһәрдәге һәм авылдагы шәкертләр шунда дини белем алганнар.

